ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2020 п.г.т.Алексеевское № 173

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының 2017 елның
22 маендагы 211 номерлы карары белән
расланган керемнәре, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре
турында, хатынының (иренең) һәм
балигъ булмаган балаларының
керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре турында
муниципаль учреждение җитәкчесе
вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук
муниципаль учреждение җитәкчесе
тарафыннан Нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**карар кылам:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 211 номерлы карары белән расланган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән вакытларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Алексеевск

муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**